Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Күкиавыл җирлеге составына керүче Күки авылы
торак пунктында үткән гражданнар җыены

# КАРАРЫ

2019 елның 30 октябре № 2

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге составына керүче Күки авылы торак пунктында үткән гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде:**

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;
2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
   - Күки авылында Ленин , Б.Урманчы, Ю.Гагарин урамнарындагы юлларга вак таш җәю;
   - Урам утлары лампалары сатып алу;
   - кышкы чорда Күки авылы эчендәге юлларны кардан чистарту һәм тәртиптә тоту;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.М.Бәдретдинов

Күки авыл җирлеге башлыгы : А.М.Бәдретдинов